ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«22» декабрь 2020нче ел

№62

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 22.06.2020 ел, №23 «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010нчы елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында "гы 2010нчы елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының раслау тәртибе турында»гы 2019нчы елның 12 августындагы 277 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 22.06.2020нче ел, №23 карарына түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

1.1.Капиталь төзелеш объектын шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында планлаштырыла торган сүтү турында хәбәрнамә һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2.Капиталь төзелеш объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында сүтелеп бетүе турында хәбәрнамәне урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нчекушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы” интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Балтач шәһәр җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе

И.Д. Габдрахманов